**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Иске Иштирәк торак пунктында гражданнар җыены карары**

2025 елның 29 ноябре № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Иске Иштирәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2025 елның 29 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Иске Иштирәк торак пункты узган территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, ветераннар һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, мобилизацияләнгән гражданнардан, контракт хезмәте хәрбиләреннән, балачактан инвалидлардан, шулай ук I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2026 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

«РИЗА» - 192 «КАРШЫ» - 0

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 349 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 192 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 292катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Иске Иштирәк торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Иске Иштирәк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Иске Иштирәк торак пункты узган территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Иске Иштирәк авылы территориясендә агачлар кисү).

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Иштирәк авылының Совет, Җиңү урамнары буенча юлларга вак таш җәю) соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Иске Иштирәк ав., Мәктәп ур., 15 й.; Бәкерав., Таулы ур., 38 й.; Ялтауав., Тынычлык ур., 27 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Иске Иштирәк авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Шәрәпова